**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАКТАЛАЧЫК**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**423751, Такталачык авылы,**
**Г.Авзалурамы,**
**48 йорт.**

**СОВЕТ**
**ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423751, село Такталачук, ул. Г.Авзал,**
**дом 48.**

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

27.11.2024ел. №3

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Такталачык авыл җирлеге составына керүче Такталачык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Такталачык авыл җирлеге Такталачык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, җирлектә 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы җыеп, түбәндәге эшләрне башкарырга:

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, суны тикшерү )тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пунктның хуҗасыз йортларын сүтү, агачларны кисү, массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү);

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

«риза» - 265, «каршы» - 0,«тоткарланучылар» - 0

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 498 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 265 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 265 граждан тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

«тоткарланучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Такталачык авыл җирлегенең Такталачык авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәсен дөрес дип танырга.

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Такталачык авыл җирлегенең Такталачык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә җыеп, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, суны тикшерү )тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пунктның хуҗасыз йортларын сүтү, агачларны кисү, массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү);

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

2. Әлеге карарны Такталачык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aktanysh.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ТР Актаныш муниципаль районы
Такталачык авыл җирлеге
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ф. Миңнеханов